КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 26 июль г.Казань № 649

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 ел, 12 июль, 565 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 ел, 12 июль, 565 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 13 март, 179 нчы; 2019 ел, 18 сентябрь, 846 нчы; 2020 ел, 28 февраль, 153 нче; 2020 ел, 17 апрель, 301 нче; 2020 ел, 25 август, 734 нче; 2020 ел, 22 декабрь, 1172 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта «23», «557,6», «18», «451,6» саннарын шул ук эзлеклелектә «26», «614,3», «21», «508,3» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле 3.4 пункт өстәргә:

«3.4. Комитет Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының $20.6^{1}$ статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүне гамәлгә ашыра.»;

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу карарның 1 пунктындагы өченче, дүртенче абзацлары 2021 елның 31 декабренә (31 декабрьне кертеп) кадәр гамәлдә була;

бу карарның 1 пунктындагы өченче, дүртенче абзацларының гамәле 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 ел, 12 июль, 565 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитетына үзгәреш кертү турында» 2020 ел, 17 апрель, 301 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин